# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Мәмдәл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**5 декабрь 2019 ел** **№1**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, уздырылган “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Мәмдәл авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

- Мәмдәл торак пунктындагы су башнясын ремонтлау, Мәмдәл һәм Юртыш авылы халкын су белән тәэмин иту эчен су башнясын сатып алу һәм кую.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 402 (дурт йез ике) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 245 (Ике йөз кырык биш) кеше, бу 60,9%ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 245 (Ике йөз кырык биш) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Мәмдәл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Мәмдәл авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”

- Мәмдәл торак пунктындагы су башнясын ремонтлау, Мәмдәл һәм Юртыш авылы халкын су белән тәэмин иту эчен су башнясын сатып алу һәм кую.

буенча кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәмдәл авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сафиуллин